**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«27» март, 2019 ел　　　　Яр Чаллы　　　　№ 1130

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2018 елның 15 маендагы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында» 1876 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1287 санлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2018 елның 15 маендагы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында» 1876 санлы карарының 12 пунктына түбәндәге абзацны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмаларның җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары размерын исәпләгәндә, кыскалык коэффициентларының III төркемен кулланырга».

2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2018 елның 15 маендагы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында» 1876 санлы карарның 1 кушымтасы исемендә «структур подразделениеләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе　　　　Л.Г. Авзалов